**Зур Кукмара авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

28 январь 2022 ел № 3

Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Байлангар авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 33 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә, 18.1 статьясын түбәндәге нигездә бәян итеп, (Зур Кукмара авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 37 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 12 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 4 номерлы, 2019 елның 27 августындагы 13 номерлы, 2021 елның 09 июнендәге 13 номерлы, 2021 елның 23 нояберендәге 25 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы: Хәнәфиев Р.Р.